ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1 – 2; 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглау – авыл хуҗалыгы җирләренең торышы һәм алардан файдалану турында дөрес мәгълүмат алуга юнәлдерелгән күзәтүләр, бәяләү һәм фаразлау системасы.»;

2) 3 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итүне дәүләт җайга салуы турында» 1998 елның 16 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында күрсәтелгән федераль дәүләт бюджет учреждениесенә авыл хуҗалыгы җирләреннән файдалану һәм аларның торышы турында, шул исәптән әлеге статьяның өченче абзацы нигезендә авыл хуҗалыгы җирләренә үткәрелгән туфрак, геоботаник һәм башка тикшеренүләр нәтиҗәләре хакында, белешмәләр тапшырырга;»;

б) дүртенче абзацны бишенче абзац дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар мондый җир кишәрлекләре турында авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә белешмәләр алырга;»;

в) бишенче һәм алтынчы абзацларны тиешенчә алтынчы һәм җиденче абзацлар дип санарга;

3) 7 статьяның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«авыл хуҗалыгы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглауны, шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт исәпкә алуын, гамәлгә ашыру;»;

4) 12 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«авыл хуҗалыгы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглауны, шул исәптән авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы торышы күрсәткечләрен дәүләт исәпкә алуын, гамәлгә ашыру;»;

5) 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«15 статья. **Авыл хуҗалыгы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглау**

Авыл хуҗалыгы җирләрен дәүләт тарафыннан мониторинглау җирләрне дәүләт тарафыннан мониторинглауның состав өлеше була һәм федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

6) түбәндәге эчтәлекле $15^1$ статья өстәргә:
«$15^1$ статья. **Авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестры**

Авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестры авыл хуҗалыгы җирләренең торышы турында, алардан файдалану хакында системалаштырылган дөрес белешмәләр һәм авыл хуҗалыгы җирләре турында башка белешмәләр җыелмасы булган дәүләт мәгълүмат ресурсыннан гыйбарәт.

Авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестрын алып бару федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белешмәләрне җыюны, гомумиләштерүне һәм аларны авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестрына тапшыруны гамәлгә ашыра.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2022 ел, 21 июнь
№ 34-ТРЗ